Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Сәрән авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

07 ноябрь 2019 ел N 3

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Сәрән авыл җирлеге
Рус Сәрәне авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Рус Сәрәне авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Татарстан Республикасы Әлмәт районы Рус Сәрәне авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Үзәк урамы, 10 нчы йорт янында.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл җирлегенең Рус Сәрәне авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Рус Сәрәне авылы өчен спорт тренажерлары сатып алу?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сәрән авыл башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Рус Сәрәне, Үзәк урамы, 15а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Сәрән
авыл җирлеге башлыгы Д.А . Севастьянов